СТАРОАЙМАНОВСКИЙ
СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
село Старое Айманово, ул.Новая,
дом5А 423739

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ АЙМАН АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Иске Айман авылы, Яна ур, 5А
йорт 423739

Тел/факс (885552)5-01-63
Saym.Akt@yandex.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
18.05.2020ел

КАРАР
№11

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлегенең 2020 елгы су коену сезоны чорында ачык сулыкларда коенуны тыю турында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Иске Айман авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 маендагы ПР-95 номерлы карары белән, Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге территориясендә пляжлар һәм суда күпләп ял итү өчен оештырылган башка урыннар булмау сәбәпле, гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклау максатларында, сулыкларда гражданнарның иминлеген тәэмин итү мөмкинлеге бирә торган, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге территориясендә урнашкан ачык сулыкларда гражданнарны 2020 елгы су коену сезоны чорында коенуны тыярга.
2. Су коену сезоны дәвамында җирлек территориясендә ачык сулыкларда су коенуны тыю һәм балаларны махсус контрольдә тоту кирәклеге турында белешмәлекләр тапшырып халык белән аңлату эшләре алып барырга.
3. Балаларның өлкәннәр тарафыннан караучысыз һәм күзәтүсез булган гаиләләрне аерым контрольгә алырга, мондый гаиләләр белән индивидуаль профилактик эш алып барырга, ата-аналарга имза астында коенуны тыю турында белешмәлекләр тапшырырга.
4. Су коенуны тыю турында ачык сулыклар янында аншлаглар куярга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында « Иске Айман авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Айман жирлеге башкарма
Комитеты Җитәкчесе ____________ Ахметханов М.Р.

Старойаймановский сельский исполнительный комитет
ИНН 1604007177
ОГРН 1061682011258